**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы №81 08 декабрь 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2015 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Советы карары белән расланган Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү Тәртибе нигезендә,

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советына әлеге карарны алган көннән алып 30 көн эчендә Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрен тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

- җирлек чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлекләрне электр, җылылык һәм газ белән тәэмин итүне оештыру;
- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук җирлек чикләрендә террорчылык һәм экстремизм чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу (әлеге мәсьәләне муниципаль район территориясендә тулаем алганда тапшырыла алмаган һәм муниципаль районның Башкарма комитетында кала торган җирле әһәмияттәге мәсьәләдән тыш), шул исәптән:

террорчылыкны профилактикалау, шулай ук минимальләштерү һәм (яисә) гамәлгә ашыру өлкәсендә муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру

җирлектә террорчылыкның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычын аңлату буенча мәгълүмати-пропаганда чараларын оештыру һәм үткәрү, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәү юлларын булдыру, шул исәптән мәгълүмати материаллар, матбугат продукциясе тарату, аңлату эшләре һәм башка чаралар үткәрү юлы белән;

террорчылыкны профилактикалау, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырыла торган аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) бетерү чараларында катнашу;

муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан сакланышына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү;

террорчылыкны профилактикалау, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырыла торган аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) бетерү чараларында катнашу;

муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан сакланышына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү;

- җирлек чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм алардан килгән зыяннарны бетерү эшендә катнашу;

- җирле традицион үсеш өчен шартлар тудыру

- Комплекслы кадастр эшләрен башкаруда 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә катнашу.

2. Татарстан Республикасы Азнакай район Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәр кабул иткән очракта, Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

- Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2018 елга һәм 2019 - 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының карар проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г. М. Төхфәтуллина